| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

8 ноября 2024 г. с.Шалты № 6

**Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегенең Шалты торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Шалты авыл җирлеге башлыгы Баулы муниципаль районы КАРАР ИТТЕ:

Билгеләргә:

- 2024 елның 23 ноябренә 10:00 сәгатькә Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлегенең Шалты торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены. Гражданнар җыенын уздыру урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Совет урамы, 63Б йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты

- 2023 елның 23 ноябренә 14:00 сәгатькә Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлегенең Шалты торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены. Гражданнар җыенын уздыру урыны-Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Новая урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан «Шалты төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

2025 елда Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән,

көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки контракт буенча хәрби хезмәткә кергән яки Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарның гаиләләреннән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Шалты авылын төзекләндерү өчен роторлы чапкыч сатып алу);

- Ихаталарны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (традицион күмү урыннарында күмүне оештыру өчен вата торган чүкеч сатып алу);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (Шалты авылындагы юлларны ремонтлау һәм карап тоту (кардан һәм чүп үләннәрдән чистарту))

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә Шалты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шалты авыл
җирлеге башлыгы З.Х. Фаткуллин